УКАЗ
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына һәм дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 24 гыйнварындагы ПУ-44 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-754 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2014 елның 22 июлендәге ПУ-708 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 25 мартындагы ПУ-285 номерлы, 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы, 2016 елның 26 ноябрендәге ПУ-1053 номерлы, 2017 елның 12 сентябрендәге ПУ-809 номерлы, 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге ПУ-1156 номерлы, 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-549 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге ПУ-697 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге ПУ-565 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 15 мартындагы 162 номерлы, 2023 елның 25 маендагы 333 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 575 номерлы, 2023 елның 2 декабрендәге 828 номерлы, 2023 елның 23 декабрендәге 902 номерлы һәм 2024 елның 11 ноябрендәге 860 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәте вазыйфалары реестрының 4 кисәге 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

«Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе 04-1-2-09»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

«Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе урынбасары 04-1-2-09[1]»;

б)

«Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе урынбасары 04-1-3-14»

позициясен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-664 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 333 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 575 номерлы, 2023 елның 2 декабрендәге 828 номерлы, 2024 елның 10 маендагы 335 номерлы, 2024 елның 18 сентябрендәге 725 номерлы һәм 2025 елның 18 апрелендәге 300 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларының 3 кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

«	Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе	04-1-2-09	3,440 »

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

«	Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе урынбасары	04-1-2-09[1]	2,669 »;

б)

«	Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты җитәкчесе урынбасары	04-1-3-14	2,669 »

позициясен төшереп калдырырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 11 март
№ 191